**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№130** **27.05.2019 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 7 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы,Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы "Бохарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен федераль законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы карар проектын хупларга һәм ачык тыңлауларга чыгарырга (кушымта теркәлә).
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы карар проектын халыкка җиткерергә.
3. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы "Бохарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2019 елның 05 июнендә 14.00 сәгатьтә Бохарай авылы мәдәният йортында үткәрергә, адресы: Бохарай авылы, Мәктәп урамы, 12А йорты.
4. Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы аппаратына ачык тыңлаулар үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.
5. Законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы каравына чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.И. Нуриев**

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ПРОЕКТЫ**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 556-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15.1 һәм 17.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 01 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Карар билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан һәм бастырып чыгарганнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Нуриев Р.И.**

Татарстан Республика
Зәй муниципаль райо
Бохарай авыл җирлеге Советының
« ___» ________ 2019 ел
___ номерлы карарына
кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

1. 6 статьяның 1 өлеше 13 пунктында "хуҗасыз йөрүче хайваннарны тотып алу һәм карап тору буенча чаралар турында» сүзләрен «хуҗасыз йөрүче хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

2. 16 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территориянең чикләре тиешле территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.»;

3. 19 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар халык, җирлек Советы, үз вәкаләтләрен контракт нигезендә башкараучы җирлек башлыгы яисә җирлек башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә.

Халык яки җирлек Советы инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар - җирлек Советы, ә үз вәкаләтләрен контракт нигезендә башкаручы җирлек башлыгы яки җирлек башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән булганда җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

4. 42 статьяның 7 өлеше 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) эшмәкәрлек белән шәхсән үзе яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнү, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, башка муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюз тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш), коллегиаль орган эшчәнлегендә Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә түләүсез катнашудан тыш; муниципаль милектә булган акцияләрне гамәлгә куючы яисә аның белән идарә итү вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә (устав капиталында катнашу өлешләре) муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (катнашучы) тарафыннан тәкъдим итү, федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

5. 47 статьяның 9 пункты 10 абзацында "хуҗасыз йөрүче хайваннарны тотып алу һәм карап тору буенча чаралар турында» сүзләрен «хуҗасыз йөрүче хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга.